КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 5 декабрь г.Казань № 1286

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа туган балалы гаиләләргә балалар кирәк-яракларының бүләк комплектларын бирү турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1100 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа туган балалы гаиләләргә балалар кирәк-яракларының бүләк комплектларын бирү турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1100 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 13 март, 129 нчы, 2021 ел, 24 май, 365 нче, 2021 ел, 15 ноябрь, 1076 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле "Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясенең хәрби хезмәткәрләре һәм анда хезмәт итүче затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт итүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә (гаилә әгъзаларына)һәм Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче яңа туган балалары булган гаиләләргә, Россия Федерациясе гражданнары, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу аркасында һәлак (вафат) булган, югарыда күрсәтелгән категорияләрдәге гражданнар гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) (алга таба – гаиләләр):» сүзләрен өстәргә:

әлеге карар белән расланган Яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

1.2 пунктның беренче абзацына түбәндәге эчтәлекле "Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар,

Россия Федерациясе милли гвардиясенең хәрби хезмәткәрләре һәм анда хезмәт итүче затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт итүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) һәм Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче яңа туган балалары булган гаиләләргә, Россия Федерациясе гражданнары, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу аркасында һәлак (вафат) булган, югарыда күрсәтелгән категорияләрдәге гражданнар гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) (алга таба – гаиләләр):» сүзләрен өстәргә:

2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясенең хәрби хезмәткәрләре һәм анда хезмәт итүче затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт итүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) һәм Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче яңа туган балалары булган гаиләләргә, Россия Федерациясе гражданнары, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу аркасында һәлак (вафат) булган, югарыда күрсәтелгән категорияләрдәге гражданнар гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) каравын раслый торга документ тапшырган очракта бала тапкан хатын-кызга балалар кирәк-яракларының бүләк комплектын бирү гаиләнең җан башына туры килә торган керемен исәпкә алмыйча гамәлгә ашырыла (балалар кирәк-яракларының бүләк комплектына хокукны билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача керем күләме турында белешмәсез).»;

2.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданның гаилә әгъзасы булган алучы гаиләнең бер кешегә исәпләнгән керем күләме турында белешмә тапшыра, ул балаларның нинди урын алып торуын бүләк итү комплектына хокукны билгеләү өчен яисә аның әлеге категориягә каравын раслый торган документ.».

2. Бу карарның гамәле 2022 елның 20 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин